**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ**
**Әлки муниципаль районы**
**Иске Алпар авыл җирлеге**
**Башкарма комитеты**

**РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН**
**Исполнительный комитет**
**Староалпаровского сельского поселения Алькеевского муниципального района**

Адресы: 422877, ТР, Әлки районы,
Иске Алпар авылы, Төньяк урамы, 29 йорт
Тел: (84346) 72553

422877, РТ, Алькеевский район,
с.Старое Алпарово, ул.Северная, д.29
Тел. 8 (84346) 72553

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

**2021 елның 20 марты** **Иске Алпар** **5№**

Татарстан Республикасы Әлки муниципаль районы Иске Алпар авыл җирлегендә җирләү буенча хезмәтләрнең гарантияле исемлеге нигезендә күрсәтелә торган хезмәтләрнең хакын раслау турында

2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы "Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында" Федераль закон, 1996 елның 12 гыйнварындагы 8-ФЗ номерлы "Җирләү һәм җирләү эше турында "Федераль закон, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2007 елның 18 маендагы 196 номерлы "Татарстан Республикасында җирләү һәм җирләү эше турында "Федераль законны гамәлгә ашыру чаралары хакында" карары нигезендә Татарстан Республикасы Әлки муниципаль районы Иске Алпар авыл җирлеге Башкарма комитеты КАРАР БИРӘ:

1. Әлки муниципаль районы Иске Алпар авыл җирлегендә 2021 елның 1 февраленнән җирләү буенча хезмәтләрнең гарантияле исемлеге буенча күрсәтелә торган хезмәтләрнең бәясен кушымта нигезендә 6424,98 сум күләмендә билгеләргә һәм гамәлгә кертергә.

2. Иске Алпар авыл җирлеге Башкарма комитетының 2021 елның 29 гыйнварындагы «Татарстан Республикасы Әлки муниципаль районы Иске Алпар авыл җирлегендә җирләү буенча хезмәтләрнең гарантияле исемлеге нигезендә күрсәтелә торган хезмәтләрнең хакын раслау турында»гы 1 номерлы карарын үз көчен югалткан дип танырга.

3. Әлеге карарны массакүләм мәгълүмат чараларында бастырып чыгарырга, Татарстан Республикасы Әлки муниципаль районының рәсми сайтында һәм Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми //htth:pravo.tatarstan.ru.порталында урнаштырырга.

4.Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз өстемә алам

Иске Алпар авыл җирлеге
Башкарма комитет җитәкчесе: Р. Р. Сәлахов

Иске Алпар авыл җирлеге Башкарма комитетының 2021 елның 20 мартындагы 5 номерлы карарына 1 нче кушымта

Иске Алпар авыл җирлегендә 2021 елның 1 февраленнән күрсәтелә торган җирләү буенча гарантияләнгән хезмәтләр исемлегенә тарифлар

| т/б№ | Хезмәтләр, кирәк-яраклар исемлеге | Хезмәт күрсәтү бәясе (сум.) |
|---|---|---|
| 1. | 1. Җирләү өчен кирәк булган документларны рәсмиләштерү | - |
| 2. | Табут һәм җирләү өчен кирәк булган башка кирәк-яракларны бирү һәм китереп бирү | 3700,80 |
| 3. | Мәрхүмнең мәетен (җәсәден) зиратка китерү | 1336,39 |
| 4. | Җирләү (каберләрне казу һәм күмү) | 1387,79 |
| | Барлыгы: | 6424,98 |

Иске Алпар авыл җирлеге Башкарма комитетының 2021 елның 20 мартындагы 5 номерлы карарына 2 нче кушымта

Иске Алпар авыл җирлегендә 2021 елның 1 февраленнән күрсәтелә торган җирләү буенча гарантияләнгән хезмәтләр исемлегенә тарифлар

| т/б№ | Хезмәтләр, кирәк-яраклар исемлеге | Хезмәт күрсәтү бәясе (сум.) |
|---|---|---|
| 1. | 1. Җирләү өчен кирәк булган документларны рәсмиләштерү | - |
| 2. | Кәфенләү(төрү, киендерү) | 1234,23 |
| 3. | Табут һәм җирләү өчен кирәк булган башка кирәк-яракларны бирү һәм китереп бирү | 2461,43 |
| 4. | Мәрхүмнең мәетен (җәсәден) зиратка китерү | 1336,39 |
| 5. | Җирләү (каберләрне казу һәм күмү) | 1392,93 |
| | Барлыгы: | 6424,98 |